ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 21 маенда
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (1 өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2; Ватаным Татарстан, 2014, 17 май) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3.2 статьяда:

а) 1 өлешнең икенче абзацында «ике йөздән алып биш йөз сумга кадәр» сүзләрен «бер меңнән алып өч мең сумга кадәр» сүзләренә, «ике меңнән алып биш мең сумга кадәр» сүзләрен «биш меңнән алып ун мең сумга кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешнең икенче абзацында «бер меңнән алып өч мең сумга кадәр» сүзләрен «өч меңнән алып биш мең сумга кадәр» сүзләренә, «йөз меңнән алып йөз илле мең сумга кадәр» сүзләрен «йөз илле меңнән алып ике йөз мең сумга кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 өлешнең икенче абзацында «бер меңнән алып өч мең сумга кадәр» сүзләрен «өч меңнән алып дүрт мең сумга кадәр» сүзләренә, «биш меңнән алып ун мең сумга кадәр» сүзләрен «ун меңнән алып унбиш мең сумга кадәр» сүзләренә, «алтмыш меңнән алып йөз мең сумга кадәр» сүзләрен «йөз меңнән алып йөз илле мең сумга кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

г) 4 өлешнең икенче абзацында «өч меңнән алып биш мең сумга кадәр» сүзләрен «дүрт меңнән алып биш мең сумга кадәр» сүзләренә, «йөз илле меңнән

алып ике йөз мең сумга кадәр» сүзләрен «ике йөз меңнән алып өч йөз мең сумга кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

2) 4.3 статьяда:

а) 1 өлешнең икенче абзацында «дүрт меңнән алып биш мең сумга кадәр» сүзләрен «кырык меңнән алып илле мең сумга кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешнең икенче абзацында «бер меңнән алып бер мең биш йөз сумга кадәр» сүзләрен «өч меңнән алып биш мең сумга кадәр» сүзләренә, «ике меңнән алып өч мең сумга кадәр» сүзләрен «егерме меңнән алып утыз мең сумга кадәр» сүзләренә, «егерме меңнән алып утыз мең сумга кадәр» сүзләрен «ике йөз меңнән алып өч йөз мең сумга кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

3) 4.4 статьяда:

а) 1 өлешнең икенче абзацында «дүрт меңнән алып биш мең сумга кадәр» сүзләрен «кырык меңнән алып илле мең сумга кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешнең икенче абзацында «бер меңнән алып бер мең биш йөз сумга кадәр» сүзләрен «өч меңнән алып биш мең сумга кадәр» сүзләренә, «ике меңнән алып өч мең сумга кадәр» сүзләрен «егерме меңнән алып утыз мең сумга кадәр» сүзләренә, «егерме меңнән алып утыз мең сумга кадәр» сүзләрен «ике йөз меңнән алып өч йөз мең сумга кадәр» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 9 июне
№ 47-ТРЗ